КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 7 сентябрь г.Казань № 838

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елда Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары нигезендә хезмәтнең махсус шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимул бирү характерындагы түләүләр, шул исәптән әлеге максатлар өчен Татарстан Республикасы тарафыннан элек тотылган чыгымнарны компенсацияләү максатларында бирелгән социаль хезмәт күрсәтүче стационар оешмалар, социаль хезмәт күрсәтүче стационар оешмаларда төзелмәгән стационар бүлекләр хезмәткәрләренең яллары өчен түләүне һәм алар файдаланмаган яллар өчен компенсация түләүне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 ел, 6 август, 659 нчы карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елда Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары нигезендә хезмәтнең махсус шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимул бирү характерындагы түләүләр, шул исәптән әлеге максатлар өчен Татарстан Республикасы тарафыннан элек тотылган чыгымнарны компенсацияләү максатларында бирелгән социаль хезмәт күрсәтүче стационар оешмалар, социаль хезмәт күрсәтүче стационар оешмаларда төзелмәгән стационар бүлекләр хезмәткәрләренең яллары өчен түләүне һәм алар файдаланмаган яллар өчен

компенсация түләүне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 ел, 6 август, 659 нчы карарына, преамбуласын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары нигезендә хезмәтнең махсус шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимул бирү характерындагы түләүләр, шул исәптән әлеге максатлар өчен Россия Федерациясе субъектлары тарафыннан элек тотылган чыгымнарны компенсацияләү максатларында бирелгән социаль хезмәт күрсәтүче стационар оешмалар, социаль хезмәт күрсәтүче стационар оешмаларда төзелмәгән стационар бүлекләр хезмәткәрләренең яллары өчен түләүне һәм алар файдаланмаган яллар өчен компенсация түләүне гамәлгә ашыруны финанслар белән тәэмин итү буенча Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында, 2020 елда финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фондының бюджет ассигнованиеләре торган Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан максатчан билгеләнештәге башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 24 июлендәге 1104 номерлы һәм «2020 елда Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары нигезендә хезмәтнең махсус шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимул бирү характерындагы түләүләр, шул исәптән әлеге максатлар өчен Россия Федерациясе субъектлары тарафыннан элек тотылган чыгымнарны компенсацияләү максатларында бирелгән социаль хезмәт күрсәтүче стационар оешмалар, социаль хезмәт күрсәтүче стационар оешмаларда төзелмәгән стационар бүлекләр хезмәткәрләренең яллары өчен түләүне һәм алар файдаланмаган яллар өчен компенсация түләүне гамәлгә ашыруны финанслар белән тәэмин итү буенча Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында, 2021 елда финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фондының бюджет ассигнованиеләре торган Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан максатчан билгеләнештәге башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 7 июлендәге 1123 номерлы карарлары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин